СОВЕТ КЕМЕШ-КУЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д.61, с. Кемеш-Куль, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422147

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КӨМЕШ-КҮЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Үзәк ур., 61 нче йорт, Көмеш-Күл авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422147

тел.(факс): (85563) 2-46-38; e-mail: KemKul.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

**Карар**

№ 3-37 21.03.2019 ел.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге Советының 2016 елның 29 июлендәге 1-10 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Россия Федерациясе Федераль законы, "Татарстан Республикасында Җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль Көмеш-Күл авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге Советы карар кабу л итте:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге Советының 2016 елның 29 июлендәге 1-10 санлы карары (№ 3-29.05.06.2018 елгы редакциядә) белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 3.2 кисәк, 3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3.2. Башкарма комитет компетенциясенә җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләр керә:

1) Җирлек Советына Җирлек бюджеты проектын раслау һәм карау, Җирлек бюджеты үтәлешен раслау, аның үтәлешен контрольдә тоту, Җирлек бюджеты үтәлеше турында хисап төзү, тапшыру;

2) Җирлекнең муниципаль милкендәге мөлкәте белән идарә итү, файдалану һәм эш итү;

3) Җирлек торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү;

4) җирлек халкын элемтә, җәмәгать туклануы, сәүдә һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;

5) авыл җирлегендә яшәүчеләрнең ялын оештыру һәм мәдәният оешмалары хезмәте күрсәтү өчен шартлар тудыру;

6) Җирлек территориясендә физик культура, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, җирлекнең рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру;

7) җирлекнең архив фондларын формалаштыру;

8) авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәүне контрольдә тотуны тормышка ашыру, күрсәтелгән Кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру;
9) объектлар адресларын бирү, адресларны үзгәртү, юкка чыгару, урам-юл челтәре элементлары исемнәрен бирү (федераль әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, региональ яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, муниципаль районның җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан тыш), җирлек чикләрендә планлаштыру структурасы исемлекләрен үзгәртү, мондый атамаларны гамәлдән чыгару, дәүләт адрес реестрында мәгълүмат урнаштыру;
10) авыл хуҗалыгы җитештерүен үстерүгә ярдәм итү, кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү өчен шартлар тудыру;
11) җирлектә балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм тормышка ашыру;
12) җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы гражданнарга һәм аларның берләшмәләренә ярдәм күрсәтү, халык дружиналары эшчәнлеге өчен шартлар тудыру;
13) каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым җыю) һәм каты коммуналь калдыкларны транспортировкалау эшчәнлеген оештыруда катнашу;
14) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;
15) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, су бүлү, халыкны ягулык белән тәэмин итү чикләрендә оештыру;
16) җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;
17) милләтара һәм конфессияара килешүне ныгытуга, җирлек территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен саклауга һәм үстерүгә, мигрантларны социаль һәм мәдәни адаптацияләүгә, милләтара (этникара) низагларны профилактикалауга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру;
18) җирлек халкы күпләп ял итә алсын өчен шартлар тудыру һәм халыкның массакүләм ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру, шул исәптән гражданнарның гомуми кулланылыштагы су объектларына һәм аларның яр буе полосаларына ирекле үтеп керүен тәэмин итү.
1.2. 4 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Башкарма комитет вәкаләтләре:

Куелган бурычларны тормышка ашыру һәм үз функцияләрен башкару өчен Башкарма комитет түбәндәге вәкаләтләрне башкара ала:
1) планлаштыру, бюджет, финанслар һәм исәпкә алу өлкәсендә:
- Җирлек бюджеты проектын эшли;
-Җирлек бюджетының үтәлешен тәэмин итә; Җирлекнең социаль-икътисади үсеш стратегиясен тормышка ашыруны оештыра;
- Җирлек бюджетының үтәлеше, Җирлекнең социаль-икътисади үсеш стратегиясен үтәү турында отчет әзерли;
- Җирлекнең икътисад һәм социаль өлкә торышын характерлаучы статистик күрсәткечләр җыюны һәм күрсәтелгән мәгълүматларны Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә дәүләт хакимияте органнарына бирүне оештыра;
- «Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында " 2014 елның 28 июнендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон белән каралган стратегик планлаштыру өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыра».

2) муниципаль милек белән идарә итү өлкәсендә, Җирлек территориясендә предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар белән үзара мөнәсәбәтләр:
- Җирлек муниципаль милкендә булган милек белән идарә итә, муниципаль милек объектларын булдыру, сатып алу, файдалану, эш белән тәэмин итү һәм арендалау буенча мәсьәләләрне хәл итә;
- Җирлек Советы карары белән билгеләнгән очракларда, Җирлек Советының килештерүенә (раславына) муниципаль милекне тартып алу, шул исәптән аны хосусыйлаштыру турында тәкъдимнәр әзерли һәм кертә;
- муниципаль милектә булмаган предприятиеләр, оешмалар белән Җирлекнең икътисадый һәм социаль үсешендә хезмәттәшлек турында килешүләр төзи; Җирлек территориясендә халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсендә төрле милек формасындагы предприятиеләр төзүгә ярдәм итә;
- Җирлек Советы тарафыннан билгеләнгән тәртип нигезендә муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр булдыра, аларның эшчәнлек шартларын һәм тәртибен билгели, аларның уставларын раслый, муниципаль казна учреждениеләрен финанслауны тәэмин итә, муниципаль учреждениеләрне һәм Предприятиеләрне үзгәртеп кору һәм бетерү мәсьәләләрен хәл итә, контракт нигезендә билгели һәм аларның җитәкчеләрен эштән азат итә;
- муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алуны гамәлгә ашыра; бюджет һәм автоном муниципаль учреждениеләр тарафыннан муниципаль йөкләмә үтәлешен финанслар белән тәэмин итә; Җирлекне төзекләндерү, халыкка коммуналь хезмәт күрсәтү, социаль инфраструктура объектларын төзү һәм ремонтлау, продукция җитештерү, халыкның көнкүреш һәм социаль - мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен кирәкле хезмәтләр күрсәтү буенча заказчы булып тора, моның өчен Җирлекнең матди һәм финанс чараларын кулланып башка эшләр башкаругa заказ бирүче булып тора;
- кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү өчен шартлар тудыра;
- депутатлар сайлаучылар белән очрашулар үткәрү өчен махсус билгеләнгән урыннар билгели, шулай ук депутатлар сайлаучылар белән очрашулар үткәрү өчен бирелә торган урыннар исемлеген һәм аларны бирү тәртибен билгели;
3) Төзелеш, транспорт һәм элемтә өлкәсендә:
- халыкны элемтә хезмәте белән тәэмин итү өчен шартлар булдыруны тәэмин итә;
- Җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыра;
4) авыл хуҗалыгын һәм эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә:
- авыл хуҗалыгы җитештерүен үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарын киңәйтү өчен шартлар тудыра, Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү өчен шартлар тудыра;
5) халыкка торак-коммуналь, көнкүреш, сәүдә һәм башка хезмәт күрсәтү өлкәсендә:
- халыкны җәмәгать туклануы, сәүдә һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыра; базар һәм ярминкәләр оештыра;
- халыкның ялын оештыру һәм мәдәният оешмалары хезмәте белән тәэмин итү өчен шартлар тудыра;
- Җирлек территориясендә физик культура, мәктәп спорты һәм массакүләм спорт үсеше өчен шартлар тәэмин итә, Җирлекнең рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чаралары үткәрүне оештыра;
- Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, су бүлү, халыкны Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә ягулык белән тәэмин итүне оештыра;
- ритуаль хезмәтләр күрсәтүне оештыра һәм күмү урыннарын карап тотуны тәэмин итә;

- аларга карата Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән таләпләр туры китереп, коммуналь инфраструктура системасын, транспорт инфраструктурасын комплексны үстерү программаларын, җирлекнең социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларын эшли һәм раслый;
- "Кулланучылар хокукларын яклау турында" 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыра;
6) төзекләндерү өлкәсендә:
- коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым җыю) һәм транспортлау буенча эшчәнлекне оештыруда катнаша;
- Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәүне контрольдә тота, күрсәтелгән Кагыйдәләр нигезендә Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыра;
- объектларга адреслар бирә, адресларны үзгәртә, юкка чыгара, урам-юл челтәре элементларына (федераль әһәмияткә ия автомобиль юлларына, региональ яки муниципальара әһәмияткә ия автомобиль юлларына, муниципаль районның җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларына тыш), Җирлек чикләрендә планлаштыру структурасы элементларына атама бирә, мондый атамаларны үзгәртә, юкка чыгара, мәгълүматны Дәүләт адрес реестрында, урнаштыра;
- Җирлек халкының күпләп ял итүе өчен шартлар тудыра һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыра, шул исәптән гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буе полосаларына ирекле үтеп керүен тәэмин итә;
7) гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен саклау, законлылыкны тәэмин итү, халыкны һәм территорияне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә:
- Җирлек территориясендә законнарның, дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнары актларының үтәлешен, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен саклауны тәэмин итә;
- билгеләнгән тәртиптә, шул исәптән судта яки арбитраж судта, җирле үзидарә хокукларын бозучы дәүләт хакимияте органнары һәм дәүләт вазыйфаи затлары, предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар актларына шикаять бирә;
- муниципаль сайлаулар, җирле референдумны әзерләү һәм үткәрүне, Җирлек Советы депутатын чакыртып алу буенча тавыш бирүне, Җирлек чикләрен үзгәртү, җирлекне үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирүне оештыру һәм матди-техник тәэмин итүне гамәлгә ашыра;
- җыелышлар, митинглар, урам йөрешләре, демонстрацияләр һәм пикетлар үткәрү, спорт, тамаша һәм башка массакүләм җәмәгать чараларын оештыру белән бәйле законнарда каралган чараларны гамәлгә ашыра;
- җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы гражданнарга һәм аларның берләшмәләренә ярдәм күрсәтә, халык дружиналары эшчәнлеге өчен шартлар тудыра;
- Җирлек торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын үткәрүне тәэмин итә;
8) мәдәният, спорт һәм балалар һәм яшьләр белән эшләү өлкәсендә:
- балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча чаралар оештыра һәм тормышка ашыра;
- милләтара һәм конфессияара килешүне ныгытуга, Җирлек территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен саклауга һәм үстерүгә, мигрантларның социаль һәм мәдәни җайлашуына, милләтара (этникара) низагларны профилактикалауга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру өчен шартлар тудыра;

9) федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен үтәү өлкәсендә:
- Җирлек федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыра;
- дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен бирелгән матди һәм финанс чараларының исәбен алып бара һәм тиешле куллануны тәэмин итә;
- гамәлдә булган федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында хисап тапшыра;
10) башка вәкаләтләр:
башка вәкаләтләр:
- җирлек башлыгы эшчәнлеген, хокукый, мәгълүмати, матди-техник һәм башка яктан оештыруны тәэмин итә;
- җирлекнең архив фондларын формалаштыруны тәэмин итә;
- гражданнарны муниципаль берәмлек Уставының 5 маддәсенең 1 бүлегене 4, 18 һәм 19 пунктларында каралган җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү максатларында Җирлек өчен әһәмиятле булган эшләрне (шул исәптән дежур торуларны) ирекле рәвештә башкаруга җәлеп итү турында Карар кабул итә һәм аларны үткәрүне оештыра;
- федераль законнар нигезендә халыкара һәм тышкы икътисадый элемтәләрне гамәлгә ашыра;
- Россия Федерациясендә муниципаль-шәхси партнерлык өлкәсендә ачык партнер булып тора һәм «Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-шәхси партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында " 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 2 өлешендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга вәкаләтле орган булып тора;
- законнарда, муниципаль берәмлек Уставында, Җирлек Советы карарлары белән Җирлек советы яки Җирлекнең башка җирле үзидарә органнары вәкаләтләреннән тыш, Җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләре буенча башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.
2.Башкарма комитет җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә кертелмәгән мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:
- Җирлек музейларын булдыра;
- Җирлектә нотариус булмаган очракта законнарда каралган нотариаль гамәлләр кыла;
- опека һәм попечительлек буенча эшчәнлекне тормышка ашыруда катнаша;
- Җирлек территориясендә җирле милли-мәдәни автономияләр хокукларын гамәлгә ашыру белән бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыра;
- Россия Федерациясе халыкларының милли-мәдәни үсешенә һәм җирлек территориясендә милләтара мөнәсәбәтләр өлкәсендә чараларны тормышка ашыруга булышлык күрсәтә;
- туризмны үстерү өчен шартлар тудыра;
- Иҗтимагый күзәтү комиссияләренә ярдәм күрсәтә, кеше хокукларын тәэмин итүгә җәмәгать контролен һәм мәҗбүри тоту урыннарында булган затларга ярдәм итүне гамәлгә ашыра;
- “Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында” 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә инвалидларның иҗтимагый берләшмәләренә, шулай ук инвалидларның бөтенроссия иҗтимагый берләшмәләре оештырган оешмаларга ярдәм күрсәтә.

- торак турындагы законнар нигезендә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарга муниципаль торак фондыннан торак урыннары бирүне оештыра;
- җирлек территориясендә яшәүче хуҗасыз хайваннар белән мөрәҗәгать итү буенча эшчәнлек алып бара;
- "Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында" 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыра;
- физик культура һәм инвалидлар, сәламәтлекләре чикләнгән затлар, адаптив физик культура һәм адаптив спорт үсешенә булышлык күрсәтә.

3. Авыл җирлеге башкарма комитеты Муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле орган булып тора.

Җирлекнең Башкарма комитетының муниципаль контроль өлкәсендәге вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Тиешле территориядә муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру;
2) җирле үзидарә органнарына бирелгән вәкаләтләр кысасында региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыру;
3) эшчәнлекнең тиешле өлкәләрендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның административ регламентларын эшләү, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнары тарафыннан расланган типлаштырылган административ регламентлар нигезендә эшләү, җирле үзидарә органнарына бирелгән региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруның административ регламентлары. Күрсәтелгән административ регламентларны эшләү һәм кабул итү Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла;
4) эшчәнлекнең тиешле өлкәләрендә муниципаль контрольнең нәтиҗәлелегенә мониторинг оештыру һәм үткәрү, аны уздыру күрсәткечләре һәм методикасы, җирлектә җирле үзидарә вәкаләтле органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган муниципаль контрольдән тыш, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан раслана;
5) федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

Муниципаль контрольне турыдан-туры гамәлгә ашыру буенча функцияләр, мондый органнарның статусын билгеләүче хокукый актлар нигезендә, Җирлекнең башкарма комитеты органнарына йөкләнергә мөмкин. Юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне тикшерүне оештыру һәм үткәрү белән бәйле мөнәсәбәтләргә карата "Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында" 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре кулланыла.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында, Мамадыш муниципаль районы http://mamadysh.tatarstan.ru/ рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге башлыгы И.Н.Сәләхетдиновка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Көмеш-Күл авыл җирлеге башлыгы,
Совет председателе

Сәләхетдинов И.Н.